## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшэр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"30" март 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 30 мартында 10сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшэр торак пунктында гражданнар Җыенының 23.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

"2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка электр җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен лампалар, автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү).
2. Авыл территориясен төзекләндерү (территорияне төзекләндерү (,үлән чапкыч сатып алу( 1 шт),үләннәрне чабу, агачларны кисү, чистарту) хезмәтләр өчен түләү).
3. Коелар төзү, ремонтлау һәм аларның территориясен төзекләндерү (Октябрь урамындагы (3шт.), Х.Такташ урамындагы (1шт.) коеларның әйләнәсен әйләндереп алу (материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү)).
4. Җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Фрунзе урамындагы чишмә әйләнәсен әйләндереп алу (1шт.) (материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү)).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 442 (дүрт йөз кырык ике) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 235 (ике йөз утыз биш) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 235 (ике йөз утыз биш) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшэр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр торак пунктында гражданнар Җыенының 23.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү” :

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен лампалар, автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү).
2. Авыл территориясен төзекләндерү (территорияне төзекләндерү (үлән чапкыч сатып алу( 1 шт.), үләннәрне чабу, агачларны кисү, чистарту) хезмәтләр өчен түләү).
3. Коелар төзү, ремонтлау һәм аларның территориясен төзекләндерү (Октябрь урамындагы (3шт.), Х.Такташ урамындагы (1шт.) коеларның әйләнәсен әйләндереп алу (материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү)).
4. Җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Фрунзе урамындагы чишмә әйләнәсен әйләндереп алу (1шт.) (материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү)).

мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшэр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Рахимзянова Г.И.